КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 3 июнь г.Казань № 765

Россия – АСЕАН саммитын уздыру чорында Казан шәһәре чикләрендә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Казан шәһәрендә Россия – АСЕАН саммитын уздыру чорында кешеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 17 июнендә 00 сәгать 00 минуттан алып 19 июнендә 24 сәгать 00 минутка кадәр Казансу елгасының 3 нче транспорт дамбасыннан алып Киров дамбасына кадәр участокта азсыешлы судноларны, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишү көймәләрен кертеп) куллануны тыюны (алга таба – тыю) билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкка тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин